**Карар № 9**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы

“19“ декабрь 2025 ел                                                                                    Яңа Шашы авылы

**Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 110 номерлы карары белән расланган “Яңа Шашы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2025 елның 21 апрелендәге 84-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 12 декабрендәге 020802-2025/Прп367-25 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге № 110 карары белән расланган (№ 124 10.02.2020 ел, № 131 28.05.2020 , № 6 30.10.2020, №37 06.12.2021 , №47 16.05.2022, №51 17.08.2022 , №84 27.10.2023 , №95 05.06.2024, №117 21.04.2025 ел үзгәрешләре белән) "Яңа Шашы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1. 21 статьяның 3 пунктының икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында** «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре ягыннан» дигән сүзләрдән соң «(гавами партнерның, капиталь грантның түләү күләмендә)» сүзләрен өстәргә;

**1.2. 21 статьяның 3 пунктының дүртенче абзацында** «Күрсәтелгән чикләү кагылмый» сүзләрен «Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән чикләүләр кагылмый» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы:                                        Сабирҗанов М.С.